КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 19 декабрь г.Казань № 1169

Төзелеш-монтаж эшләре кыйммәтен индексацияләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип санау турында

Капиталь төзелеш объектлары төзелеше кыйммәтен оптимальләштерү һәм тотрыклыландыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт программалары белән күздә тотылган капиталь төзелеш объектларын яңадан төзи башлау өчен 2020 елның 1 гыйнварыннан федераль бердәм бәяләр база дәрәҗәсенә карата (өстәлгән кыйммәткә салымнан тыш) капиталь төзелеш объектларының төзелеш-монтаж эшләре кыйммәте үзгәрү индексларын (төзелеш төрләре, эшләр төрләре һәм тармаклар буенча) бу карарга теркәлгән кушымта нигезендә билгеләргә.

2. Капиталь төзелеш объектларының бу карар белән исәпкә алынмаган төзелеш төрләре, эшләр төрләре һәм тармаклары өчен төзүчеләр (техник заказчылар) тарафыннан төзелеш, реконструкция һәм ремонт эшләре кыйммәте төп материалларга, конструкцияләргә һәм әйберләргә агымдагы бәяләрнең Татарстан Республикасы буенча төзелеш ресурсларына бәяләр мониторингы нәтиҗәсендә билгеләнгән уртача дәрәҗәсен исәпкә алып, ресурс методы белән куела дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы буенча төзелеш ресурсларына бәяләр мониторингын Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының ведомство буйсынуындагы «Татарстан Республикасының Төзелеш һәм архитектура буенча дәүләт экспертизасы һәм бәя билгеләү идарәсе» дәүләт автоном учреждениесе гамәлгә ашыра дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип санарга:

«Төзелеш-монтаж эшләре кыйммәтен индексацияләү турында» 2015 ел, 24 март, 183 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеш-монтаж эшләре кыйммәтен индексацияләү турында» 2015 ел, 24 март, 183 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 ел, 5 сентябрь, 651 нче;

«Төзелеш-монтаж эшләре кыйммәтен индексацияләү турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1081 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин